**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «21» сентябреннән № 233

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсендәге хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында»**

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының бюджет өлкәсендәге хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсендәге хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 5.08.2020 ел, № 655 карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының "Яңа Чишмә муниципаль районының хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 207 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 18.07.2018 ел, № 290 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) билгеләнгән тәртиптә бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет өлкәсенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдәге бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең секретаренең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм арттырган вакыттагы (индексация) түләүләр күләме тулы сумга кадәр арттыру ягына түгәрәкләндерелергә тиеш;

әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә) шулай ук Татарстан Республикасы_Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**